СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**«22» март 2024 ел.** **№ 2**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Чулпан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 23 ноябрендәге 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Чулпан авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Кәче авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпанн авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 нче елның 23 нояберендәге 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Чулпан авылында гражданнар җыенының беренче этабын Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорты адресы буенча 2024 елның 05 нче апреленә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 нче елның 23 нояберендәге 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Чулпан авылында гражданнар җыенының икенче этабын Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорты адресы буенча 2024 елның 05 нче апреленә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Гагарин, Яңа, Чокырлы урамында яшәүчеләр

2нче этап: Тимер юл, М.Җәлил, Түбән урамында яшәүчеләр.

4. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Чулпан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 нче

ноябрендәге 2 нче номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:
«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт челтәрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү,төзекләндерү, карап тоту (Чулпан авылының Яңа урамында, М.Җәлил урамында юл полотнасын ямау юлы белән төзекләндерү)?»

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

5. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Чулпан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 23 нче ноябрендәге 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6.Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендында: ТР, Арча районы, Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гәрәев